**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**

# КАРАР

10.02.2016 Яр Чаллы № 320

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының һәм Тукай муниципаль районы бюджеты акчаларын алучы (бүлүче) казна учреждениеләре бюджет сметаларын төзү, раслау һәм алып бару тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 158, 161, 162, 221 статьялары, «Казна учреждениеләренең бюджет сметаларын төзү, раслау һәм алып бару тәртибенә гомуми таләпләр турында» 2007 елның 20 ноябрендәге 112н номерлы Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы (2015 елның 1 декабрендәге 190н номерлы редакциясендә), Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2013 елның 5 декабрендәге 413 номерлы боерыгы нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының һәм Тукай муниципаль районы бюджеты акчаларын алучы (бүлүче) казна учреждениеләре бюджет сметаларын төзү, раслау һәм алып бару тәртибен расларга.
2. Башкарма комитетның 2010 елның 24 декабрендәге 5758 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Финанс-бюджет палатасы рәисе Л.Н. Хуҗагалеевага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Р.В. Асылгәрәев